

11-12нче январьдә республика кvлә-мендә татар теле һәм әдәбияты буенча ярышларнын республика турлары М.Е.Евсевьев исемендәге педагогия институты филология фәннәр факультетында vтте. Анда муниципаль турда жинvчеләр катнашты. Алдагы елларда урнашкан традиция буенча, шул ук конне, шул ук бинада мордва (мукшы, эрзә) телләре һәм әдәбияты буенча XXI регионара олимпиадасынын шулай ук республика этабы vтте.

Мордовия мәгариф министрлыгы белгече Надежда Васильевна Салмова әнгәмәсендә болай ди: «Туган тел олимпиадаларында муниципаль турларда жингән барлыгы 150 укучы коч сынады. Республика кvләмендә татар теле һәм татар әдәбияты буенча vткән олимпиадаларда барлыгы 32 укучы катнашты. Татарстан мәгариф һәм фән министрлыгы белгечләре әзерләгән биремнәр буенча эш итте укучылар. Биремнәр безнен укучылар очен бик кызыклы булды дигән фикердә мин, чонки ниндидер рәсемнәр буенча да жавапларын язып бирделәр.



Олимпиадаларда башкарган бирем-нәр Мордовия мәгариф министрлыгы раслаган жюри әгъзалары белән тикшерелде һәм баллар куелды; жинvчеләр белән призерлар тантаналы котлау вакытында әйтелер. Бvген нәтижәләр район мәгариф бvлекләренә электрон вариантта жибәрелде».

Бу чарага зур кызыксыну Мордовиянен торле телевизион һәм газет чаралары уятты. Корреспондентларга оештыручылар һәм олимпиадада катнашучылар рәхәтләнеп интервью бирделәр; телевизион тапшыруларда кvрдек инде.

Рузаевка районы Татар Пешлә урта мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы Сания Спартак кызы Саляе-ва ярыш турында фикерләре белән уртаклашты. Ул:

«…институтта олимпиадалар матур гына оештырылып килә, - ди. -Быел мин татар теле буенча республика ярышына муниципаль турда жинеп чыккан 11нче сыйныф укучысы Кузиков Ильдарны, 10нчы сыйныфтан Чугунова Камилланы (ул әдәбият буенча ярышта да катнашты), 9нчы сыйныфтан Касимова Сабина белән Биксаляева Диананы алып килдем. Биремнәргә килгәндә, укучыларым татар теле биремнәре чишәрди дип әйттеләр, ә татар әдәбияты буенча - авыррак булулары турындагы фикерләрен ишеттем. 

Мәгариф министрлыгыннан жи-бәрелгән ярыш нәтижәләрендә укучы-ларымнын унышлары кvренә - баллары югары».
Ярышта катнашучылар алдагы тормыш планнары белән дә уртаклаштылар. Аларнын байтагы label педининститутка укырга керергә уйлыйлар һәм бирәдә бу чаранын vткәрелvе алдан уйланып куелган. МГПИнын кабул итv шартлары да мона яраклаштырылган. Шулай, алдагы елларнын кvп кенә олимпиада жинvчеләре филология факультетынын студентлары булдылар. Мәсәлән, Качкова Алина (Ләмберә районы Пензятка урта мәктәбе), Илькаева Регина (Ромодан районы Алтар урта мәктәбе) һәм башкалар. Ә бит филология факультетына туган  мордва (мукшы, эрзә), татар мәдәниятларынын vзенчәлекләрен, гореф-гадәтләрен, телләрен саклау һәм vсеше очен жаваплылык ята. Алар студентларга халыкара дуслык орлыгы салучы да.

**Наилә Насырова**